**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ 12.09.2024 № ПР-165 № ____

Иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Түке авыл җирлеге, Зөбәер авылы, Үзәк урам - «Фельдшер-акушерлык пункты», Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Түке авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре шәхси торак төзелеше зонасы адресы буенча урнашкан, 16:04:200201:509 кадастр номерлы, 1000 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

1) Нуртдинов Рамил Мирхаҗиян улы
2) Галиәхмәтов Айнур Кәрим улы
3) Зәйнетдинов Булат Рифат улы
4) Галимова Зөлфирә Сабирҗан кызы

3. Җәмәгать фикер алышуларын (гавами тыңлауларны) оештыручыга Түке авыл башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) үткәрү 14.09.2024 елдан да соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.Т.Демидовка йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов